**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

От «11» января 2019 г. № 3

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Об утверждении муниципальной программы “Развитие национального образования в Атнинском муниципальном районе”

В целях сохранения и развития системы национального образования, сохранения и развития национальной культуры и языка, в соответствии с Концепцией развития национального образования в Республике Татарстан до 2030 года, утвержденной Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 19.08.2016 г. № 570Государственной программой "Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 - 2020 годы", утвержденной Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 25.10.2013 N 794 постановляю:

1. Утвердить программу «Развитие национального образования в Атнинском муниципальном районе на 2019-2022 гг.» согласно приложению.
2. Настоящее постановление вступает в силу со дня его подписания.

И.о. руководителя Атнинского районного исполнительного комитета: А.Ф.Каюмов

**Лист**

**согласования, адресования, ознакомления**

к постановлению №__3__ от __11.01.19г.__

«Об утверждении муниципальной программы «Развитие национального образования в Атнинском муниципальном районе»

Исполнитель: Начальник МКУ «Отдел образования» Л.Т. Гарипов.

Согласовано:

| Должность | Ф.И.О. | Подпись и дата |
|---|---|---|
| Ведущий специалист МКУ «Отдел культуры» | Касимова А.Р. | |
| Ведущий специалист исполнительного комитета | Галлямова Р.М. | |

# 2019-2022 ЕЛЛАРГА ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ

ОЛЫ ӘТНӘ

**2019-2022 ЕЛЛАРГА ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019-2022 елларга Әтнә муниципаль районында милли мәгарифне үстерү программасы |
| Программаның эшләү өчен нигез | - 2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы<br>- 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Милли мәгариф үсеше Концепциясе. |
| Программаны төп эшләүче | Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәге. |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Татарстан Республикасының дәүләт телләрен саклау,өйрәнү, үстерү өчен шартлалар тудыру, “Татарстан Республикасы Дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында “ ТР Законы , 2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне, өйрәнү һәм үстеру буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2019-2022 еллар |
| Программаның төп юнәлешләре | -районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә яна федераль белем бирү стандартларына күчү шартларында дәүләт телләрен өйрәнү,<br>-икетеллелек шартларында педагогик кадрлар белән эшләү,<br>-дәүләт телләренең иҗтимагый статусын күтәрү,<br>-татар телен республикадан читтә үстерү, саклау. |
| Программаны үтәүчеләр | Әтнә муниципаль районының мәгариф бүлеге, мәгълүати-методик үзәк, мәктәпкәчә,башлангыч, урта, профессиональ, өстәмә белем бирү учреждениеләре. |
| Программа үтәлешен тикшереп тору<br><br>Финанслау чыганагы | Программа үтәлешен Әтнә районы администрациясе тикшерә.<br>Муниципаль бюджет<br>2019 елга – 400000<br>2020 елга –400000<br>2021 елга – 400000<br>2022 елга – 400000<br><br>Барлыгы - 1600000 |

# I. ПРОБЛЕМАНЫҢ АСЫЛЫ

“Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы республика халыклары телләренең ирекле үсеше өчен кирәкле шартлар белән тәэмин итә. Закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыруда һәм телләрнең гамәлдә булуы өчен төп юнәлеш мәгарифкә юнәлгән.

“Мәгариф турында” РФ һәм РТ Законнарына, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Законына, 2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү Татарстан Республикасы дәүләт программасына туры китереп, Әтнә муниципаль районында милли мәгарифкә нигез салучы принцип булып, туган телдә белем һәм тәрбия алу хокукы һәм бу хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыру тора.

Милли мәгариф шәхесенең интеллектуаль һәм рухи үсеше өчен киң мөмкинлекләр ача. Әтнә районында аның үсеш проблемалары чишелгән: мәктәпләрдә югары белемле тел һәм әдәбият укытучылары эшли, татар телендә белем алу өчен бөтен мөмкинлекләр булдырылган.

Әтнә районы территориясендә 13 балалар бакчасы, 7 филиал, 1 башлангыч мәктәп-бакча, 7 төп, 5 урта белем бирү учреждениесе эшләп килә, мәктәпләрдә 1116, балалар бакчаларында 510 бала белем һәм тәрбия ала.

**2018-2019 уку елында укучыларның милләт составы (Таблица 1)**

| | |
|---|---|
| **Татарлар** | 97 % |
| **Башка милләт** | 3,04 |

**Милли белем бирү учрежденияләре (Таблица 2)**

| Гомуми белем бирү учрежденияләре | Барлыгы | Татар телендә белем бирү учрежденияләре |
|---|---|---|
| Урта мәктәпләр | 5 | 5 |
| Төп мәктәпләр | 7 | 7 |
| Мәктәп филиалы | 7 | 7 |
| Балалар бакчалары | 13 | 13 |
| Башлангыч мәктәп-бакча | 1 | 1 |
| Барлыгы | 33 | 33 |

Районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары “Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыру шартларынд, татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүнең нәтиҗәлеген күтәрү” дигән методик тема өчтендә эшлиләр.

Әтнә районы мәктәпләрендә 24 татар теле һәм әдәбият укытучысы эшли, барысы да югары белемле. Район мәгариф бүлеге һәм мәктәп планы буенча һәр укытучы үз вакытында Татарстан Республикасының Белем үстерү иститутында профессиональ дәрәҗәләрен күтәрәләр. 21 укытучы ( 88 %) квалификацион категориягә ия. Шуларның 11 ( 46 %) югары квалификацион категорияле, 10 укытучы (42 %) I квалификацион категорияле.

Мәктәпләрдә татар телендә белем бирелә, татар мәктәпләре өчен чыккан программалар белән эшлиләр.

Барлык гомуми белем бирү учрежденияләре татар телендә белем бирүче предмет укытучылары белән тәэмин ителгән.Алдагы елларда педагогик кадрларга ихтыяҗ юк.

Районыбыз укучылары мәктәп, район, республика күләмендә уздырылган бәйгеләрдә катнашалар.

**(Таблица 3)**

| **№** | **Мәктәп** | **Татар теле (район этабы)** | | **Татар әдәбияты (район этабы)** | | **Республика олимпиадасы** | | **Халыкара олимпиада** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | җиңүче | призер | җиңүче | призер | Татар теле | Татар әдәбияты | Татар әдәбияты |
| 1 | О.Әтнә | 3 | 4 | 1 | 3 | 1катнашучы | | |
| 2 | Күңгәр | 1 | 2 | 2 | | | **1 призер,** 1 катнашучы | катнашучы |
| 3 | Күәм | | 2 | | | | | |
| 4 | Комыргуҗа | | 1 | 1 | | | **1 призер** | катнашучы |
| 5 | Бәрәскә | | | | | | | |
| 6 | О.Мәңгәр | 2 | 3 | | | | | |
| 7 | Т.Көек | 1 | | | | | | |
| 8 | Күшәр | | 1 | | | | | |
| 9 | Бәрәзә | 1 | 1 | | | 1катнашучы | | |
| 10 | И.Өҗем | | | | 1 | | | |
| 11 | К.Киме | | 2 | | | | | |
| 12 | Я. Шашы | | 1 | | | | | |

Барлык мәктәпләрдә дә күренекле шәхесләргә, язучыларның юбилейларына багышланган чаралар үтә. Февраль анда Ш.Мәрҗәни исемендәге Коморгуҗа урта мәктәбендә Ш.Мәрҗәни исемендәге республикакүләм фәнни-гамәли конференция уздыру мәгариф һәм фән министрлыгының эш планына кертелде. Конференциядә Арча, Саба, Кукмара, Теләче, Яшел Үзән, Биектау, Балтач һәм башка районнардан укучылар, укытучылар, галимнәр катнаша. Киләчәктә дә, ике елга бер тапкыр бу конференцияне үткәрү планлаштырылды. Февраль аенда Халыкара туган телләр көне зурлап

үткәрелә. Апрель аенда һәр мәктәптә татар теле һәм әдәбияты айлыгы үткәрелә.

Мәктәпләрдә фәннәрне укытуны камилләштерү, сәләтле балаларны ачыклау максатыннан районда ел саен татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадалар үткәреләә.

Районда 13 татар теле һәм әдәбияты кабинеты эшли. Барысы да бүгенге көн таләпләренә туры килә, зәвык белән бизәлгән, бай иҗат лабораторияләре тупланган, санитар-гигиена нормалар, куркынычсызлык кагыйдәләре үтәлә.

Үткәрелгән чараларга нәтиҗәләр ясала, нәтиҗәләр предмет укытучылары киңәшмәләрендә, район методберләшмә утырышларында анализлана, мәгариф бүлеге буенча приказлар чыгарыла, җиңүчеләр бүләкләнә.

Районның татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методберләшмәсе белән Күңгәр урта мәктәбенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галиева Гөлфия Фирдәвесовна җитәкчеле итә. Методберләшмәнең эше укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрүгә, укыту-тәрбия процессына яңа технологияләр кертүгә юнәлтелгән.

Әтнә районы Мари Эл республикасының Морки районы Нурумбал урта мәктәбе белән тыгыз элемтәдә эшли. Нурумбал мәктәбенең укытучылары районда үткәрелгән семинарларда актив катнаша. Нәтиҗәле эш алып барыла.Нурумбал мәктәбе әдәби китаплар белән тәэмин ителде.

## ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ.

Максатлар:

1. Татар телен милли мәдәният, тулы кыйммәтле аралашу чарасы һәм татар халкын берләштерү нигезе буларак саклау, өйрәнү һәм үстерү;
2. Рус телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак саклау һәм үстерү;
3. Сөйләм культурасының гомуми дәрәҗәсен һәм телләр арасында толерантлыкны үстерү;
4. РФ регионнарында (Мари Эл Республикасы, Башкортостан Республикасы) яшәүче татар халкына татар телен саклауга һәм үтерүгә ярдәм итү;
5. Тел традицияләренә сакчыл мөнәсәбәт булдыру, телгә аңлы рәвештә милли-мәдәни хәзинә итеп карауны тәрбияләү;
6. Татарстан Республикасының дәүләт телләрен грамоталы белү дәрәҗәсен күтәрү өчен шартлар тудыру.

**Бу максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:**

1. Белем бирү өлкәсендә татар теле стаусын күтәрү, татар телендә белем һәм тәрбия бирүче учреждениеләр челтәрен саклау һәм үстерү, халыкларны үзара рухи һәм мәдәни баетуда аның функцияләрен киңәйтү.
2.Татар һәм рус телләренең, дәүләт теле буларак, тигез хокуклы һәм оптималь эшләвен тәэмин итү.
3.Сөйләм культурасының гомуми дәрәҗәсен һәм телләр арасында толерантлыкны үстерү.
4. Рус телен Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак өйрәнү өчен шартлар тудыру.

## ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ.

- Татар теле укытуның укыту-методик һәм укыту-материаль базасын ныгыту.
- Татар теле укытучыларының квалификациясен күтәрү.
- Рус теле нормаларын белү, тел грамоталыгы һәм сөйләм культурасы дәрәҗәсен күтәрү чараларын күрү.
- Татар халкының күпләп яшәү урыннарында мәгариф учреждениеләренә татар телен саклап калу,өйрәнү, үстерү эшендә ярдәм итү.
- Республикадан читтә татар телендә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен укыту-методик әдәбият белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү.
- Республикадан читтәге китапханә фондларын татр телендәге китаплар белән тулыландыруга ярдәм итү.
- Укытуның заманча яңа ысулларын, үзенчәлекле иллюстратив һәм күрсәтмә ярдәмлекләр куллану.

## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ СТРУКТУРАСЫ

1. Әтнә районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә дәүләт телләренең гамәлдә булуын тәэмин итү һә өйрәнү.
2. Икетеллелек шартларында педагогик кадрлар белән эш.
3. Дәүләт телләренең иҗтимагый статусын күтәрү.
4. Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү.

# 2019-2022 ЕЛЛАРГА ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ЧАРАЛАРЫ

| № | ЧАРАЛАР | ҮТӘЛҮ ВАКЫТЫ | ҖАВАПЛЫ |
|---|---|---|---|
| **I БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЯЛӘРЕНДӘ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ.** | | | |
| 1. | Гомуми белем бирү учрежденияләрендә дәүләт телләрен өйрәнүне тәэмин итү. | Бөтен чорда | Әтнә районы мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк |
| 2. | Гомуми белем бирү учрежденияләрендә ел саен Татарстан дәүләт телләре буенча олимпиадалар үткәрү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре |
| 3. | Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты буенча чыгарылыш имтиханнары, БДИ, БРТ үткәрү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре |
| 4. | Мәгариф учрежденияләренең бизәлешендә (стендлар,плакатлар һ.б.) татар телен куллануны тәэмин итү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре |
| 5. | Район күлмендә уздырыла торган чараларны Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә үткәрү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре,мәдәният бүлеге |
| 6. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен өйрәнү кабинетларының укыту-матди базасын заманча баһазлар, яңа буын иллюстратив материаллар, күргәзмә әсбаплар белән ныгытуга ярдәм итү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре |
| 7. | Туган телдә гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә даими рәвештә белем бирү процессының | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мониторингын ясау. | | мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре |
| 8. | 2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы һәм 2019-2022 елларга Әтнә муниципаль районында милли мәгарифне үстерү программаларн гамәлгә ашыру буенча чаралар планын төзү. | Ел саен | Мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре, мәдәният бүлеге |
| 9. | Программа һәм чаралар планы үтәлеше буенча анализ ясау. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре, мәдәният бүлеге |
| 10. | Укучыларның район территориясендә музейларга йөрүен оештыру. | Бөтен чорда | Мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре, мәдәният бүлеге |
| 11. | Тел фәннәре буенча белем бирү сыйфатына мониторинг ясау | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре |
| **II. ИКЕТЕЛЛЕЛЕК ШАРТЛАРЫНДА ПЕДАГОГИК КАДРЛАР БЕЛӘН ЭШ** | | | |
| 1. | Милли гомуми белем бирү учреждениеләренә педагогик кадрларны әзерләү, квалификацион категорияләрен күтәрү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк |
| 2. | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының квалификацион категорияләрен күтәрү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре |
| 3. | Район укытучыларының татар телендә иң яхшы дәрес, чараларның эшкәртмәләрен туплау. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | методик үзәк, мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре |
| 4. | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының “Ел укытучысы” район конкурсында катнашуларын тәэмин итү. | График буенча | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре, “Әтнә таңы” газетасы редакциясе. |
| 5. | Уку елы нәтиҗәләре буенча ( республика олимпиадалары, конкурслары, фестивальләре призерларын әзерләү) татар теле һәм әдәбияты укытучыларын бүләкләү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре |
| 6. | Милли гомуми белем бирү учреждениялəренең яшь укытучыларына педагогик осталыкларын күтәрүдә ярдәм итү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре |
| **III. ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ СТАТУСЫН КҮТӘРҮ.** | | | |
| 1. | Татар һәм рус телләре айлыкларын оештыру һәм үткәрү | Ел саен | Мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре |
| 2. | Китапханә фондларын милли һәм туган як әдәбияты белән тулыландыру. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениялəре җитәкчеләре |
| 3. | Гомуми белем бирү учреждениялəрендә татар теле һәм әдәбияты кабинетларының смотр конкурсын үткәрү. | 3 елга 1 тапкыр | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк. |
| 4. | Район гомуми белем бирү учреждениялəре укучылары арасында иң яхшы шигырь укучы, иншалар, рәсемнәр конкурслары үткәрү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | учреждениялəре җитəкчелəре, “Əтнə таңы” газетасы редакциясе. |
| 5. | Гомуми белем бирү учреждениялəре,башлангыч һəм урта белем бирү учреждениялəре укучылары өчен Ш.Мəрҗəни исемендəге фəнни-гамəли конференцияне оештыру һəм үткəрү. | 2 елга 1 тапкыр | Район мəгариф бүлеге, мəгълүмати-методик үзəк, мəгариф учреждениялəре җитəкчелəре, “Əтнə таңы” газетасы редакциясе. |
| 6. | Районда милли бəйрəмнəр, конкурслар,фестивальлəр үткəрүдə ярдəм итү. | Бөтен чорда | Район мəгариф бүлеге, мəгълүмати-методик үзəк, мəгариф учреждениялəре җитəкчелəре, “Əтнə таңы” газетасы редакциясе,җирле үзидарə органнары. |
| 7. | Массакүлəм мəгълүмат чараларында районда милли мəгариф үсешенең уңышларын һəм проблемаларын чагылдыру. | Бөтен чорда | Район мəгариф бүлеге, мəгълүмати-методик үзəк, мəгариф учреждениялəре җитəкчелəре, “Əтнə таңы” газетасы редакциясе. |
| 8. | Татар халкының күренекле мəдəният, сəнгать,əдəбият əһеллəре белəн очрашулар оештыруга ярдəм итү. | Бөтен чорда | Район мəгариф бүлеге, мəгълүмати-методик үзəк, мəгариф учреждениялəре җитəкчелəре, “Əтнə таңы” газетасы редакциясе,җирле үзидарə органнары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Районның күренекле җәмәгать эшлеклеләре, язучылары, журналистлары белән очрашулар оештыру. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре, “Әтнә таңы” газетасы редакциясе. |
| 10. | Уку елы нәтиҗәләре буенча гомуми беле бирү учреждениеләренең сәләтле укучыларын бүләкләү. | Ел саен | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре. |
| 11. | Тел укытучыларының иң яхшы материалларын район мәгариф бүлеге сайтына урнаштыру, “Әтнә таңы” газетасына бастыру. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре, “Әтнә таңы” газетасы редакциясе. |
| 12. | Әтнә районы җирлегеннән чыккан язучылар, шагыйрьләр, күренекле шәхесләрнең юбилейларына багышлап район күләмендә чаралар оештыру, үткәрү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре,мәдәният бүлеге,җирле үзидарә органнары. |
| **IV. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫННАН ЧИТТӘ ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ. РЕГИОННАР БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК (Мари Эл республикасы Морки районы)** | | | |
| 1. | Татар телендә дәреслекләр,методик әсбаплар,аудио һәм видеоматериаллар, матур әдәбиятбелән тәэмин итүгә булышлык итү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Татар телен укытучы педагогик кадрларга методик ярдәм күрсәтүдә булышлык итү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк. |
| 3. | Татар теле һәм мәдәнияте көннәрен оештыруга булышлык итү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк,мәдәният бүлеге. |
| 4. | Морки районы Нурумбал мәктәбе укучылары белән очрашулар үткәрү. | Бөтен чорда | Район мәгариф бүлеге, мәгълүмати-методик үзәк, мәгариф учрежденияләре җитәкчеләре, мәдәният бүлеге. |